РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » 06 2023 г. №808

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 09.11.2021 № 921 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2014 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 12 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында" 31.12.2022 № 109-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы халкын үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 26.07.2021 № 655 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 09.11.2021 № 921 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль

автоматлаштырылган системасы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы карарларына һәм күрсәтмәләренә һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга  һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина